**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# «Татарстан Республикасының Инвестиция декларациясе турында» Татарстан Республикасы Президенты Указына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле берәмлекләре органнарының Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеген башкару өчен уңайлы шартлар булдыру буенча эшчәнлеген камилләштерү максатында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының Инвестиция декларациясе турында» 2012 елның 18 июнендәге ПУ-477 номерлы Указына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында уңайлы инвестиция мохитен булдыру өчен шартлар тудыру, «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә капитал салуны яклау һәм хуплауны тәэмин итү максатында, Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының 2021 елның 30 сентябрендәге 591 номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясе субъектының Инвестиция декларациясен әзерләү буенча методик тәкъдимнәрне исәпкә алып, **карар бирәм:**»;

б) кушымтада бирелә торган Татарстан Республикасының Инвестиция декларациясен яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** — **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ · АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2021 ел, 30 ноябрь
№ ПУ-920

Татарстан Республикасы
Президентының
2021 елның «30» ноябрендәге
ПУ-920 номерлы Указына
кушымта

# Татарстан Республикасы Инвестиция декларациясе

## I. Татарстан Республикасының инвестицион үсеше максатларының гомуми тасвирламасы

1.1. Татарстан Республикасы Инвестиция декларациясе түбәндәге максатларда эшләнде:

Татарстан Республикасында инвестиция проектларын гамәлгә ашыру өчен уңай инвестиция климатын тәэмин итү;

халкының тормыш дәрәҗәсен яхшырту өчен Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешен тәэмин итү;

эшкуарлык эшчәнлеген тотрыклы алып бару һәм үстерү өчен шартлар булдыру.

1.2. Татарстан Республикасының инвестицион үсешенең төп максаты – милли үсеш максатына ирешүгә кертем буларак төп капиталга инвестицияләрнең реаль үсешен 2030 елга кадәр 2020 ел күрсәткече белән чагыштырганда 70 процентка җиткерү (Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы мәгълүматлары буенча 2020 елда – 605 763,4 млн сум).

1.3. Татарстан Республикасы Инвестиция декларациясе эшкуарларга дәүләт ярдәме чараларының һәм эшкуарлык эшчәнлеге алып бару шартларының какшамаслыгы, аларның актуальлеге, ачыклыгы һәм нәтиҗәлелеге турында мәгълүмат бирергә тиеш.

1.4. Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге башкару «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы Татарстан Республикасы Законына нигезләнеп җайга салына. Татарстан Республикасы инвестиция проектларына ярдәм итүне бер тәрәзә принцибы буенча Татарстан Республикасы инвестицион үсеш агентлыгы (алга таба шулай ук – Агентлык) башкара.

1.5. Татарстан Республикасында эшкуарлык эшчәнлегенә ярдәм итүнең эш урыннары булдыруга, өстәмә бәянең үсүенә һәм салым күчерүгә китерүче төп капиталга инвестицияләр җәлеп итү һәм аларның күләмен арттыру мөмкинлеген бирүче чаралар эшләнде һәм актив кулланыла.

1.6. Татарстан Республикасында инвестиция процессында катнашучыларның инвестиция эшчәнлеген башкарганда тигез хокуклы булуын тәэмин итү гарантияләнә, конкурентлыкны үстерү хуплана.

1.7. Татарстан Республикасында ташламалы режимда эшкуарлык эшчәнлеге алып бару инвестиция мәйданчыкларының, махсус икътисадый зоналарның (МИЗ) һәм Татарстан Республикасының алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләрен дә кертеп, аларның гамәле дәвамында эшчәнлегенә ярдәм итү гарантияләнә.

## II. Татарстан Республикасына төп характеристикалар

2.1. Татарстан Республикасы – Россия Федерациясенең алга киткән сәнәгать, фәнни, авыл хуҗалыгы, инновация байлыклары булган социаль-икътисадый үсеш ягыннан алдынгы субъекты.

Татарстан Республикасының мәйданы 67 837,4 кв. километр тәшкил итә, республика составына 43 муниципаль район һәм ике шәһәр округы керә.

Төп макроикътисадый күрсәткечләр буенча республика Россия Федерациясе төбәкләре арасында алдынгы позицияләрне саклап кала (Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының 2020 елга эшчәнлеге турында хисап мәгълүматлары буенча):

тулай төбәк продукты – 6 урын;
сәнәгать җитештерүе – 4 урын;
авыл хуҗалыгы – 4 урын;
торак тапшыру – 5 урын;
төзелеш – 6 урын;
төп капиталга инвестицияләр – 6 урын;
ваклап сату әйләнеше – 7 урын.

Татарстан Республикасында Россиядә чыгарыла торган полиэтиленның 27,7 проценты, синтетик каучукның 38,7 проценты, Россиядә чыгарыла торган йөк автомобильләре өчен шиннарның һәр икенчесе, Россиядә чыгарыла торган йөк автомобильләренең һәр өченчесе җитештерелә.

2.2. Татарстан Республикасы территориясе инвестиция проектларын гамәлгә ашыру өчен барлык кирәкле шартларга ия.

Татарстан Республикасының географик урыны Россия Федерациясенең көнчыгыш һәм Европа өлешләренең транспорт элемтәләрен тәэмин итүдә, шулай ук башка илләр белән бәйләнешләрдә аның төп ролен билгели. Татарстан Республикасында транспортның барлык төрләре дә бар: халыкара «Казан» һәм «Бигеш» аэропортлары, «Бөгелмә» төбәк аэропорты, дүрт елга порты, сигез федераль юл, автомобиль һәм тимер юлларның тармакланган челтәрләре эшли. Транспорт инфраструктурасы бүлү һәм логистика үзәкләре, шул исәптән мультимодаль үзәкләр белән тәэмин ителгән.

Россия Федерациясендәге федераль салым ташламалары бирелгән мәйданчыкларның иң күбесе Татарстан Республикасында – алар җидәү. Республика территориясендә ике МИЗ – сәнәгать-җитештерү төрендәге «Алабуга» һәм техник-кулланышка кертү төрендәге «Иннополис», шулай ук биш алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе бар: «Чаллы», «Түбән Кама», «Чистай», «Зеленодольск» һәм «Менделеевск». Инвестиция

мәйданчыклары булдырылды, шул исәптән сәнәгать парклары, муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыклары, технополис, технопарклар бар.

Татарстан Республикасында инвесторларга дәүләт ярдәме чаралары, шул исәптән Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары һәм муниципаль норматив хокукый актлары нигезендә каралган салым ташламалары бирелә. Алар турында мәгълүмат Татарстан Республикасының Инвестиция порталында бирелә.

2.3. Татарстан Республикасы Хөкүмәте, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башка органнары үз вәкаләтләре кысаларында Россия Федерациясе законнары нигезендә инвестиция эшчәнлеген алып бару өчен кирәкле килешүләр һәм рөхсәт документларын килештерү һәм бирү срокларын үтәүне тәэмин итәләр.

2.4. «2030 елга кадәр Татарстан Республикасында социаль-икътисадый үсеш стратегиясен раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасында 2030 елга кадәр социаль-икътисадый үсеш стратегиясе (алга таба – Стратегия) расланды. Стратегия нигезендә Татарстан Республикасында үстерелә торган өстенлекле тармаклар түбәндәгеләр:

химия һәм нефть химиясе сәнәгате;
машина төзелеше һәм металл эшкәртү;
мәгълүмат технологияләре һәм телекоммуникацияләр;
агросәнәгать комплексы;
төзелеш;
медицина һәм фармацевтика;
хезмәт күрсәтү һәм туризм;
фәнни эшләнмәләр.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан инвестиция үсешенең өстенлекле юнәлешләре билгеләнгән Татарстан Республикасы Инвестиция меморандумы өч елга, шулай ук өстенлекле инвестиция проектлары исемлеге ел саен раслана.

2.5. Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге «Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге турында» 2010 елның 2 августындагы 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә алып барыла. Республикада хуҗалык һәм фәнни эшчәнлекнең инфраструктур элементлары булдырылган, алар эшчәнлек төрләре, башкарыла торган функцияләрнең характеры һәм күләме, күрсәтелә торган хезмәтләр һәм инновация эшчәнлегенә дәүләт ярдәме ысуллары белән аерылып тора. Фән, технологияләр һәм техника үсешенең өстенлекле юнәлешләрен, шулай ук критик технологияләр исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

2.6. Татарстан Республикасы икътисадын үстерү Татарстан Республикасының тулай төбәк продуктының түбәндәге структурасы белән билгеләнә (2020 ел бәяләмәсе буенча):

файдалы казылмалар чыгару – 24,1%,
эшкәртү сәнәгате – 16,7%,

сәүдә – 10,9%,

авыл хуҗалыгы – 6,2%,

транспортта ташу һәм саклау – 6,2%,

төзелеш – 7,7%.

Татарстан Республикасы сәнәгатендә эшкәртү производстволары өлеше 70 % тәшкил итә. Республикада чыгарыла торган нефтьнең 60 проценты эшкәртелә. Сәнәгать производствосының гомуми күләмендә инновация продукциясенең өлеше 22,2 % тәшкил итә. Чимал булмаган экспорт республика экспорт структурасында 65 проценттан артып китте.

2021 ел йомгаклары буенча Татарстан Республикасының тулай төбәк продукты 2 907,8 млрд сум дәрәҗәсендә бәяләнә яки узган ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 103,8 процент тәшкил итә (Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы мәгълүматлары буенча).

Ел саен республика икътисадына һәм социаль өлкәгә 600 млрд сумнан артык инвестиция кертелә. Татарстан Республикасы Хөкүмәте бюджет акчаларын инфраструктура төзелешендә, шул исәптән инвестиция проектларын гамәлгә ашыруда актив куллана.

2.7. Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлегенә дәүләт ярдәме өчен кирәкле үсеш институтлары һәм инструментлары булдырылды.

Татарстан Республикасы инвестицион үсеш агентлыгы эшли, ул инвестиция проектларын гамәлгә ашыру өчен иң уңайлы шартлар тудыруга юнәлдерелгән төбәк үсеш институты булып тора.

Агентлыкның төп бурычлары:

инвестицияләр җәлеп итү;

дәүләт-хосусый партнерлыгын үстерү;

Татарстан Республикасының инвестиция мөмкинлекләрен таныту.

Агентлык Татарстан Республикасының икътисадына инвестицияләр җәлеп итү мәсьәләләре буенча коллегиаль киңәшмә орган – Татарстан Республикасының Инвестиция советы эшчәнлеген оештыру-техник һәм мәгълүмат-аналитик яктан тәэмин итүне башкара, аның рәисе – Татарстан Республикасы Президенты.

Татарстан Республикасында Татарстан Республикасының Инвестиция порталы (invest.tatarstan.ru), шулай ук инвестор өчен кирәкле башлангыч мәгълүмат бирелгән Татарстан Республикасының Инвестиция картасы эшли. Инвесторның «клиент юлы»н цифрлаштыру кысаларында порталда инвестиция проектын электрон рәвештә алып бару өчен гариза бирү мөмкинлеге булдырылды, алга таба ул проект буенча проблемалы мәсьәләләрне бетерү яки эш башкару вакытын файдалырак куллану буенча Агентлык тарафыннан эшләр башкару өчен проектны гамәлгә ашыру статусы буенча ведомствоара хезмәттәшлек алып бару мөмкинлеге белән инвестицион проектларны мониторинглауның мәгълүмати системасында Агентлык тарафыннан эшкәртелә.

## III. Татарстан Республикасының инвестиция йөкләмәләре

3.1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үз вәкаләтләре чикләрендә түбәндәге инвестиция йөкләмәләрен башкаруны гарантияли:

инвестиция проектларын тормышка ашыру өчен шартларның начарланмавын;

дәүләт хезмәтләреннән, муниципаль һәм башка хезмәтләрдән файдаланганда процедураларның срокларын һәм санын киметүне;

Россия Федерациясе законнары нигезендә инвестиция эшчәнлеген башкару өчен кирәкле рөхсәт документларын килештерү һәм алу срокларын үтәүне һәм киметүне;

Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция проектларын гамәлгә ашырганда туган бәхәсле мәсьәләләрне судка кадәрге тәртиптә карап тикшерүнең срокларын киметүне;

Татарстан Республикасы территориясендә инвесторлар өчен инвестиция эшчәнлегенә дәүләт ярдәме чаралары турында мәгълүматның, дәүләт һәм федераль законнар тарафыннан саклanылучы сер булып торган мәгълүматтан тыш, гомумкулланышта булуын;

Татарстан Республикасында инвесторларга дәүләт ярдәме чаралары күрсәтү өчен шартларның кичекмәстән үтәлүен;

Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыру максатлары өчен ресурсларның конкурентлы нигездә бүленүен тәэмин итүне;

Татарстан Республикасы халкының керем дәрәҗәсен арттыруны.

## IV. Татарстан Республикасының инвестиция командасы

4.1. Татарстан Республикасының инвестиция командасы составына түбәндәгеләр керә:

Татарстан Республикасы Президенты;

Татарстан Республикасы Премьер-министры һәм аның урынбасарлары, шул исәптән Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы икътисад министры;

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил – Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе;

Татарстан Республикасы инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыклары (килешү буенча);

«Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәгать палатасы» берлеге рәисе (килешү буенча);

«Россия сәнәгатьчеләр һәм эшкуарлар берлеге» гомумроссия иҗтимагый оешмасының «Татарстан Республикасы Предприятиеләр һәм сәнәгатьчеләр ассоциациясе (эш бирүчеләрнең төбәк берләшмәсе) төбәк бүлекчәсе генераль директоры (килешү буенча);

«ОПОРА РОССИИ» гомумроссия кече һәм урта эшкуарлык иҗтимагый оешмасының Татарстан республика бүлекчәсе рәисе (килешү буенча);

«Эшлекле Россия» гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлекчәсе рәисе (килешү буенча);

«Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча);

«Иннополис» махсус икътисадый зонасы» акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча);

«Татнефтехиминвест-холдинг» акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча);

«Татарстан Республикасы Инвестиция-венчур фонды» коммерциячел булмаган оешмасы директоры (килешү буенча);

«Татарстан Республикасының эшкуарлыкка булышлык фонды» коммерциячел булмаган микрокредит компаниясе генераль директоры (килешү буенча).

4.2. Инвестиция декларациясе максатына ирешү, шул исәптән Татарстан Республикасы инвестиция командасы эшен оештыру белән бәйле мәсьәләләр Татарстан Республикасы Инвестиция советы утырышларында карала.

---